КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 27 декабрь г.Казань № 1250

Тукай муниципаль районында җир кишәрлекләрен бер категориядән икенче категориягә күчерү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы, Тукай муниципаль районы башкарма комитетының Тукай муниципаль районында урнашкан, шулардан 6,4734 гектары – дәүләт милкендә, 0,8 гектары «Тукай муниципаль районы Калмия авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге милкендә, 0,0903 гектары Тукай муниципаль районы Комсомол авыл җирлеге башкарма комитеты милкендә булган 7,3637 гектар гомуми мәйданлы авыл хуҗалыгы әһәмиятендәге җир кишәрлекләрен түбәндәге кадастр саннары белән Күчемсез милекнең бердәм дәүләт реестрыннан өземтәләрдә күрсәтелгән чикләрдә ритуаль эшчәнлек объектларын урнаштыру максатларында сәнәгать җирләре һәм башка махсус әһәмияттәге җирләр категориясенә күчерү турындагы тәкъдимен кабул итәргә:

| Җир кишәрлегенең кадастр саны | Мәйданы, гектар |
|---|---|
| 16:39:132001:13 | 2,8884 |
| 16:39:132001:14 | 0,1568 |
| 16:39:132001:15 | 0,6731 |
| 16:39:131202:661 | 0,8 |
| 16:39:120601:1136 | 0,1049 |
| 16:39:120601:1138 | 0,174 |
| 16:39:121201:97 | 1,4448 |
| 16:39:210701:21 | 1,0314 |
| 16:39:210701:22 | 0,0903 |
| Барлыгы | 7,3637. |

2. Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрына билгеләнгән тәртиптә тиешле үзгәрешләр кертүне тәкъдим итәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин